КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2023 ел, 19 июль г.Казань № 865

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының кайбер карарларына үзгәрешләр кертү турында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасын социаль-икътисадый үстерү буенча уңышлы тәҗрибәләрне һәм инициативаларны сайлап алу буенча ведомствоара региональ комиссия төзү турында» 2018 ел, 12 сентябрь, 770 нче карарына (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2019 ел, 1 август, 638 нче; 2019 ел, 26 октябрь, 963 нче; 2020 ел, 6 апрель, 259 нчы; 2020 ел, 19 декабрь, 1164 нче; 2021 ел, 12 апрель, 241 нче; 2021 ел, 7 декабрь, 1190 нчы; 2022 ел, 18 август, 857 нче; 2023 ел, 6 апрель, 424 нче карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

3 пунктта «Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте башкарма органнары» сүзләрен «республика башкарма хакимият органнары» сүзләренә алмаштырырга;

әлеге карар белән расланган Татарстан Республикасын социаль-икътисадый үстерү буенча уңышлы тәҗрибәләрне һәм инициативаларны сайлап алу буенча ведомствоара региональ комиссия турындагы нигезләмәнең 3.1 пунктындагы өченче абзацында «Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте башкарма органнары» сүзләрен «республика башкарма хакимият органнары» сүзләренә алмаштырырга.

2. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы территориясендә милли социаль инициатива механизмнарын гамәлгә ашыру буенча проект офисын төзү турында» 2020 ел, 18 декабрь, 1150 нче карары белән расланган Татарстан Республикасы территориясендә милли социаль инициатива механизмнарын гамәлгә ашыру буенча проект офисы турындагы нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

3.1 пунктта:

икенче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«эштә катнашу өчен Татарстан Республикасы закон хакимияте органнары, республика башкарма хакимият органнары, федераль башкарма хакимият органнарының территориаль органнары, Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләренең җирле үзидарә органнары, иҗтимагый һәм башка оешмалар вәкилләрен җәлеп итәргә;»;

өченче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Татарстан Республикасы территориясендә милли социаль инициатива механизмнарын гамәлгә ашыру максатларында республика башкарма хакимият органнары, шулай ук федераль башкарма хакимият органнарының территориаль органнары, Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләренең җирле үзидарә органнары, иҗтимагый һәм башка оешмалар өчен методик тәкъдимнамәләр әзерләргә;»;

дүртенче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«үз компетенциясе чикләрендә республика башкарма хакимият органнарыннан, федераль башкарма хакимият органнарының территориаль органнарыннан, Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләренең җирле үзидарә органнарыннан, иҗтимагый һәм башка оешмалардан эшче төркем тарафыннан карарлар кабул итү өчен кирәкле мәгълүмат соратып алырга;».

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин